РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

# КАРАР

**2020 ел 1 июнь** **№ 51-17**

## Тәтеш муниципаль районы Советының «Тәтеш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында»гы 2014 елның 24 мартындагы 46-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәтеш муниципаль районы Советының «Тәтеш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында»гы 2014 елның 24 мартындагы 46-4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәтеш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә керә торган вазыйфаларны һәм вакантлы идарәче вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәнең II бүлегендәге 17 өлешенең 5 абзацын «хезмәт кенәгәсе» сүзтезмәсеннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзтезмәсе белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.А. Гасимовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**